КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 октябрь г.Казань № 938

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында

Җәмәгатьчелеккә объектив мәгълүмат бирүне, гражданнарның хокукларын саклауны, М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлаганда һәм төзегәндә барлыкка килә торган мәсьәләләрне үз вакытында карауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем составы.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының 2020 ел,
17 октябрь, 938 нче карары белән
расланды

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем (алга таба – М-12 трассасы) эшчәнлеге халыкның фикерен исәпкә алуны тәэмин итүгә, М-12 трассасын проектлаганда һәм төзегәндә барлыкка килә торган мәсьәләләрне үз вакытында һәм тулы карауга юнәлдерелгән, җәмәгатьчелек вәкилләрен үз эченә алган ведомствоара коллегиаль орган булып тора.

## II. Эшче төркемнең төп бурычлары

Эшче төркемнең төп бурычлары түбәндәгеләр:
эшләр башкару нигезләре һәм этаплары турында халыкка үз вакытында хәбәр итүне тәэмин итү;
М-12 трассасын проектлаганда һәм төзегәндә барлыкка килгән мәсьәләләрне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хәл итү ;
М-12 трассасын төзегәндә хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылган Татарстан Республикасында торак пунктларда яшәүчеләрнең хокукларын саклау;
дәүләт хакимиятенең федераль һәм республика башкарма органнары, муниципаль органнар, иҗтимагый оешмалар һәм җәмәгатьчелек вәкилләренең гомуми хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру;
М-12 трассасын проектлау һәм төзү белән бәйле мөлкәт-хокукый мәсьәләләрне үз компетенциясе кысаларында хәл итүгә ярдәм итү.

## III. Эшче төркемнең хокуклары

Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:
Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), иҗтимагый һәм башка оешмалар (килешү буенча) вәкилләрен эшкә җәлеп итәргә;
үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан эшче төркем тарафыннан тиешле карарлар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга.

## IV. Эшче төркемнең эш тәртибе

Эшче төркем утырышлары, кирәк булган саен, аның җитәкчесе карары буенча, ә ул булмаганда яки җитәкче кушуы буенча – җитәкче урынбасары карары буенча үткәрелә. Эшче төркем әгъзалары утырышны үткәрү турында тәкъдимнәр кертергә һәм көн тәртибен тәкъдим итәргә хокуклы.

Җитәкче, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча эшче төркем җитәкчесе урынбасары утырышларда рәислек итә, көн тәртибен раслый, эшне планлаштыра һәм эшче төркем карарларын тормышка ашыруны контрольдә тота.

Утырышларны үткәрү датасы һәм көн тәртибе эшче төркем җитәкчесе тарафыннан, ә ул булмаганда яки җитәкче кушуы буенча – җитәкче урынбасары йөкләмәсе буенча раслана.

Эшче төркем эшендә, кирәк булганда, аның составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре катнаша ала.

Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, эшче төркем җитәкчесе тарафыннан , ә ул булмаганда яки җитәкче кушуы буенча– аның урынбасары тарафыннан имзалана һәм аның барлык әгъзаларына утырыш уздырылган көннән соң биш эш көне эчендә җибәрелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 октябрь, 938 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә М-12«Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Хәнифов Фәрит Мөдәрис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры, эшче төркем җитәкчесе |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары, эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Дементьев Дмитрий Викторович | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлегенең Орел авылында яшәүче, эшче төркем җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Зарипов Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары |
| Зарипов Илдус Фатыйх улы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Мәдифуров Руслан Рәфикъ улы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлегенең Орел авылында яшәүче (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Карина Вячеслав кызы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең Кызыл Иль авылында яшәүче (килешү буенча) |
| Трофимова Марина | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге |

| | |
|---|---|
| Викторовна | өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Шиһапов Айрат Минимарсиль улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары. |

---